ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 14 ноябре** **Чистай шәһәре** **№ 724**

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү программасын раслау турында» 2022 елның 15 сентябрендәге 612 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү программасын раслау турында» 2022 елның 15 сентябрендәге 612 номерлы карары белән расланган 2022-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспортында «Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан финанслау» түбәндәге сүзләренә алмаштырырга:
«Программаны җирле бюджет хисабына финанслауның гомуми күләме 5800 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Җирле бюджет акчалары |
|---|---|
| 2022 | 2900 |
| 2023 | 2900 |
| Барлыгы | 5800»; |

1.2. 7 бүлектә икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Җирле бюджет хисабына түбәндәге чаралар финанслана:

(мең сум)

| Чараның исеме | Акча күләме | |
|---|---|---|
| | 2022 ел | 2023 ел |
| Шәхси ярдәмче хуҗалыклар алып баручы гражданнарга сөт юнәлешендәге мини-фермалар төзү чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр бирү | 400 | 400 |
| Шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сөт эре мөгезле терлекләрне тотуга матди ярдәм күрсәтү (саву аппаратлары бирү рәвешендә) | 2500 | 2500»; |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет<br>
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов